

28 яшьлек Әхмәт Садретдин улы Симаев (1915-1944) - Боек Ватан сугышында, Советлар Союзы Герое Муса Жәлил һәм анын корәштәшләре белән, 1944 елнын 25 августында Плетцензее тормәсендә фашистлар жәзалап vтергән татар әдипләренен берсе.
Әхмәт Симай псевдонимлы шагыйрь, журналист 1915 елнын 28 декабрендә бvгенге Краснослободск районы Усть-Рахмановка авылында (элек Пенза губернасы булган) туган. Башлангыч мәктәпне туган авылында тәмамлаган, аннан жиде еллык Старое Синдрово авылы мәктәбендә 1925-1928 елларда укыган. Садретдин улы Әхмәт укыган мәктәп Старое Синдрово авылында урнашкан һәм бvген анда мордва–мукшы һәм рус халкы яши. Алар татар батыры турындагы тарихны саклый: мәктәп диварына истәлек тактасы 1987 елда куелган, фотолары һәм анын турында мәгълумат язып эленгән. Мәктәп укучылары тикшеренv эшләре алып баралар, хәтта Әхмәт Симаевнын абыйсы Фәттах белән хат язышканнар. Ул хатлар, балаларнын эшләре мәктәп музеенда саклана.

1928 елда Мәскәvгә кvчкән, читтән торып тозелеш техникумында укыган. Мәскәv метрополитены тозелешендә эшләгән. Әхмәт Садретдин улы яшьлегендә «Метростроитель» дигән татарча газетада эшләгән. Урысча язган кайбер язмалары астына, авыл исемен vзгәртеп, А.Влиндор (Валиндур) дигән әдәби псевдоним куя торган булган.
Татар ижтимагый мәдәни vзәгендә Муса Жәлил белән танышкан. 1938 елдан Воскресенск шәһәрендәге «Коммунист» газетасы редакциясендә эшләгән. Редакциядә эшләгән Валентина Листопад белән гаилә корган. Кызлары Людмиланы ул кvрми кала, чонки 1940 елда армиягә китә. Радист-десантник була. Боек Ватан сугышы башлангач, сугышка китә. 1942 елда әсирлеккә эләгә. Әсирлектә «Идел-Урал» комитетынын радиостудиясендә тәржемәче була. Әхмәт Симаевнын vлеменә кагылышлы кәгазьне 1958 елда немец галиме, эзтабар язучы, тәржемәче, журналист, Леон Небенцаль (1910-

1991) эзләп тапканлыгы мәгълvм: “Әхмәтнен, Гайнан Кормаш, Абдулла Баттал һәм Фоат Булатов кебек, сугышка кадәр vк Җәлил белән таныш булганлыгы, аларнын даими кvрешеп һәм аралашып яшәгәнлекләре билгеле. Тоткынлыкка эләккән Мусаны Гайнан Кормаш торкеменә алып килvче дә – Әхмәт Симаев. Гомумән, тикшерvче-эзләнvчеләр әлеге атаклы торкемнен башында торучыларнын берсен Гайнан Кормаш дип санаса, икенчесен сугыш вакытында разведчиклар мәктәбен бетергән Әхмәт Симаев дип фаразлый”.
1944 елнын 25 августында фашист палачлары 11 җәлилче белән бергә Әхмәт Симаевны гильотинада җәзалап vтерә. Унбер гомер, шуларнын алтысы язучылар.
Әхмәт Симаевнын Дрезден тормәсендә утырганда диварга мондый сvзләр язып куйганлыгы мәгълvм: «Здесь сидел Ахмет Симаев, журналист, москвич. Нас из России одинадцать человек. Все мы осуждены вторым германским имперским судом на смертную казнь. Кто обнаружит это надпись и вернется живым на Родину, прошу сообщить родным и близким о нашей судьбе. 22 март, 1944 ел». Дивардагы ошбу язуны капитан Лукъянов кvреп ала һәм бу хакта 1945 елнын 20 июнендә Әхмәт Симаевнын хатынына хәбәр итә.
Анлатма кертик. Мордовиядә ике Усть-Рахмановка бар. Атюрьево районы Усть-Рахмановкасын Яна Аллагол дип тә йортә жирле халык, ә икенче Усть-Рахмановка Краснослободск рай-онындагысын Валендур диләр. Валендурга Яна Аллагол кешеләре нигез салган. Әхмәт Симаев та нәкъ Усть-Рахмановка-Валендурда туа. Бу авыл турында интернеттагы мәгълvматларга караганда, Валендур атамасы мукшы телендә “Урманга чой булып кергән” дигәнне анлата. Чынлап та бу авыл урман эчендә урнашкан. Авылнын урысча атамасы биредәге Рахман елгасыннан алынган. Валендурны XVI гасырда темников татарлары нигезли. 1869 елда авылда 168 йорт булган. 1894 елда исә 252 йортта 1751 кеше яшәгән, 3 мәчет һәм 3 мәктәп эшләгән. 1931 елда авылда 70 хужалык һәм шуларда 396 яшәvче исәпләнгән. Аннары саннар азайганнан – азая барган. Хәзерге вакытта 20 кеше теркәлгән, кешеләр яши торган йортлар саны 2-3тән артмый. Әлеге авылда җәйләрен кvбрәк кеше яшәсә дә, кышларга 4-5 кеше кала.
Атюрьево районы Татар Тенишево авылында гомер итvче Равилә Шекур кызы Такмамышева мәктәптә 40 елдан артык татар телен укытты, лаеклы ялда булуына карамастан, актив рәвештә тарихи эзләр буенча татар халкынын милли мирасын барлауда катнаша. Саранск шәһәрендә укытучыларнын белем камилләштерv институтында курслар vткәндә таныштык без анын белән һәм шунда ул Әхмәт Симаев турында белгән мәгълуматын безгә житкерде. Альбом да ясаган иде, институт хәзер юк, шулай ук альбом да.
Бер нәрсә йорәкне тырный: Мордовиябез жире талантларга бай, шул исәптән тарларыбыз арасында да олы шәхесләребез байтак. Әмма без аларнын исемнәрен тиешенчә мәнгеләштермәгәнбез. Әхмәт Симаев бик кочле шәхес булган. Исемен мәнгеләштерv мәсьәләсенә игътибар кирәк, чонки җәлилчеләр тарихы әле дә кvпләрне шаккатыра.

**Наилә НАСЫРОВА әзерләде**